ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2019 ел № 29/7

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Бюджет кодексына, 2018 елның 19 июлендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм "Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" Федераль законның 4 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 222-ФЗ санлы Федераль законга, 2018 елның 27 декабрендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 504-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6, 2015 елның 22 октябрендәге 2/14, 2016 елның 24 февралендәге 6/6, 2017 елның 24 октябрендәге 20/5, 2018 елның 21 февралендәге 23/7, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/5 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 5 һәм 6 өлешләр белән тулыландырырга:

«5.Башкарма комитет билгели:

1) муниципаль программалар һәм аларның структур элементлары киселешендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибен, шулай ук муниципаль программаларга карамаган эшчәнлек юнәлешен;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибен.

6. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

2) 8 маддәнең 12 өлешендәге тугызынчы абзацта «(килешүләр) субсидияләр бирү турында» сүзләреннән соң товарлар җитештерү (сату), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә;

3) 8 маддәнең 12 өлешендәге унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән субсидияләрне шәһәр бюджетыннан бирү тәртибе, әгәр ул әлеге өлешнең уникенче абзацында каралган нигездә карар белән билгеләнмәгән булса, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә. Субсидияләрне шәһәр бюджетыннан бирү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләргә туры килергә тиеш.»;

4) 8 маддәнең 14 өлешендәге өченче абзацта «субсидияләр бирү турында килешүләр буенча йөкләмәләр» сүзләреннән соң «субсидия алучыларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен» сүзләрен өстәргә;

5) 8 маддәнең 14 өлешен түбәндәге эчтәлектәге сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 маддәсендәге 2 һәм 4 пунктларда каралган тәртиптә шәһәр бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр һәм күрсәтелгән килешүләргә үзгәрешләр кертү яисә аларны өзүне күздә тотучы өстәмә килешүләр Башкарма комитетның финанслар идарәсе тарафыннан расланган типовой формалар буенча төзелә.»;

6) 8 маддәнең 14.1 өлешендәге бишенче абзацта «1 һәм 8 пунктларда» сүзләрен «1,7,8 пунктларда» дип үзгәртергә;

7) 8 маддәнең 14.1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзац белән тулыландырырга:

«Әлеге өлешнең бишенче абзацында күрсәтелгән субсидияләр бирү турында килешүләр һәм күрсәтелгән килешүләргә үзгәрешләр кертү яисә аларны өзүне күздә тотучы өстәмә килешүләр Башкарма комитетның финанслар идарәсе тарафыннан расланган типовой формалар буенча төзелә.»;

8) 8 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 19 өлеш белән тулыландырырга:

«19. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78, 78.1, 78.3 һәм 80 маддәләрендә каралган тәртиптә субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре бирү өчен аларны алучыларның шәһәр бюджеты алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга

салынмаган) бурычы булмавы шарт, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш.»;

9) 15 мадданең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль бурыч алулар шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бурыч йөкләмәләрен түләү, финанс елы дәвамында шәһәр бюджеты счетларында калган акчаларны тулыландыру максатларында гамәлгә ашырыла.»;

2.Әлеге Карар рәсми бастырылган көненнән үз көченә керә, 1 пунктның 1 пунктчасы өчен гамәлгә керү вакыты – 2020 елның 01 гыйнварыннан соң.

3.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме　　　　　　　　　　　　　　　　Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ